РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
«25» 02 2026 ел.

КАРАР
№ 30

**Татарстан Республикасы Әтнә район Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 №505-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Әтнә районы прокуратурасының 29.01.2026 №02-08-03-2026/Прдп 31-26 тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кылды:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 04.08.2017 №77 карарын;

Әтнә район Советының «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Әтнә район Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 28.06.2021 №54 карарының 4 пунктын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш. Хисамиев